КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 6 сентябрь г.Казань № 665

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Илһам Шакиров исемендәге республика премиясе турында» 2020 ел, 22 август, 723 нче карары белән расланган Илһам Шакиров исемендәге республика премиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Илһам Шакиров исемендәге республика премиясе турында» 2020 ел, 22 август, 723 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 2 сентябрь, 945 нче; 2023 ел, 3 март, 202 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Илһам Шакиров исемендәге республика премиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Премия шәхси характерда һәм түбәндәге номинацияләр буенча һәм түбәндәге күләмнәрдә бирелә:

«Вокал (хатын-кызлар)» – 200,0 мең сум күләмендә бер премия;

«Вокал (ир-атлар)» – 200,0 мең сум күләмендә бер премия;

«Халык җыры (хатын-кызлар)» – 200,0 мең сум күләмендә бер премия;

«Халык җыры (ир-атлар)» – 200,0 мең сум күләмендә бер премия.»;

2.5 пунктта «Халык җыры» номинациясе» сүзләрен «Халык җыры (хатын-кызлар)» һәм «Халык җыры (ир-атлар)» номинацияләре» сүзләренә алмаштырырга;

3.7.2 пунктның беренче абзацында «Халык җыры» номинациясе» сүзләрен «Халык җыры (хатын-кызлар)» һәм «Халык җыры (ир-атлар)» номинацияләре» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин